**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«27» 04 2021 ел Яр Чаллы №1261

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы 1 өлеше һәм Тукай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 23 апрелендәге 9/7 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.
2. Расларга:

Тукай муниципаль районының административ комиссиясе составын (1 кушымта);

Тукай муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын (2 кушымта).

3. Тукай муниципаль районы административ комиссиясенең вәкаләтләре вакыты әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.
4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 октябрендәге 5415 номерлы карары, 2018 елның 2 ноябрендәге 5352 номерлы карары (2018 елның 8 декабрендәге 5922 номерлы, 2020 елның 10 августындагы 3029 номерлы, 2020 елның 26 октябрендәге 4142 номерлы карарлары) үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22.04 1261 номерлы карарына 1 кушымта

Тукай муниципаль районының административ комиссиясе составы

Хәбибуллин Айрат Рафак улы – Башкарма комитеты Җитәкчесе – комиссия рәисе;

Бузина Нәзирә Камил кызы – Тукай муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы – комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча);

Яппарова Алинә Фәрид кызы – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты баш белгече, административ комиссиянең җаваплы секретаре.

Комиссия әгъзалары:

Попова Екатерина Викторовна – Тукай муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге баш белгече (килешү буенча);

Морзаханова Чулпан Филгать кызы – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты гомуми бүлегенең баш белгече (килешү буенча);

Исхакова Гөлназ Гаяз кызы – район Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Шамин Сергей Сергеевич – Тукай муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының әйдәп баручы белгече (килешү буенча).

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27.04 1268 номерлы карарына 2 кушымта

**Тукай муниципаль районының административ комиссиясе регламенты**

Әлеге Регламент Тукай муниципаль районының административ комиссиясенең (алга таба – административ комиссия) эш тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Административ комиссия Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан төзелгән.

Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) һәм Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

Административ комиссия административ хокук бозулар турында эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында эш итә.

Административ комиссиянең бурычы булып административ хокук бозулар турында һәр эшне Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә һәрьяклы, тулы, объектив һәм үз вакытында карау, чыгарылган карарның үтәлешен тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү тора.

Административ комиссиянең вәкаләтләр срогы әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре срогына кадәр. Күрсәтелгән срок узганнан соң административ комиссия үз вәкаләтләрен яңа составтагы административ комиссиянең беренче утырышы көненә кадәр гамәлгә ашыруны дәвам итә.

Административ комиссия әгъзаларының вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе административ комиссиянең үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча билгеләргә тиеш.

Административ комиссиянең тулы исеме булган мөһере бар.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

Административ комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, административ комиссиянең җаваплы секретареннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба – административ комиссия әгъзалары) тора, алар Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

Административ комиссиянең шәхси һәм санлы составы 5 кешедән дә ким булмаган санда Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм так сан булырга тиеш.

Даими штат нигезендә административ комиссия составына административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, административ комиссиядә җәмәгать башлангычларында эшли.

Административ комиссиянең башка әгъзалары Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары буенча үз вазыйфаларын даими түләүле нигездә җирле бюджет акчалары хисабына башкара алалар.

Административ комиссия рәисе рәис урынбасарлары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасында вазыйфаларны бүлә, Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә аларның функцияләрен билгели.

Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы секретаренең квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

Административ комиссия килүчеләрне кабул итә ала. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

Административ комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан кергән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

Административ хокук бозулар турында эшләр административ комиссиядә саклана һәм 5 елдан соң Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегенә тапшырыла.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

Административ хокук бозулар турында эшләрне карау административ комиссия тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Административ хокук бозулар турында эшләр административ комиссия утырышларында карала. Административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар, административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен, әмма кимендә ярты елга бер тапкыр, аның рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда, рәис билгеләгән рәис урынбасарларының берсе тарафыннан кабул ителә.

Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турында эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган ешлык белән үткәрелә.

Административ комиссиянең җаваплы секретаре административ комиссия

әгъзаларына административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышына кадәр кимендә 2 көн кала хәбәр итә.

Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары бу хакта административ комиссия утырышына кадәр, кагыйдә буларак, 1 эш көне кала, административ комиссиянең җаваплы секретаренә хәбәр итәргә тиешләр.

Административ комиссия утырышы, әгәр анда административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була.

Административ хокук бозу турында эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 4. Административ җәза бирү турында карарның үтәлеше

Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә үтәлә.

Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарларның, билгеләмәләрнең һәм күрсәтмәләрнең эш буенча производствода катнашучы затлар, башка физик һәм юридик затлар тарафыннан үтәлешен административ комиссиянең җаваплы секретаре контрольдә тота.

## 5. Административ хокук бозуларны профилактикалау

Административ хокук бозуларны кисәтү максатында, административ комиссия үз эшчәнлеген эчке эшләр органнары, Суд приставлары федераль хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

Административ комиссия рәис раслаган график нигезендә күчмә утырышлар үткәрә, шул исәптән муниципаль район җирлекләрендә дә.

Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре алып бару юлы белән профилактик эш оештыра.